ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
КШКЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

# КАРАР

1 ноябрь 2024 ел № 4

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2024 елның 12 ноябренә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Кышлау авылы Совет урамы 4 нче йорттан 42 нче йортка кадәр, Тукай урамы 1 нче йорттан 37 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2024 елның 13 ноябренә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Кышлау авылы Татарстан урамы 1 нче йорттан 43 нче йортка кадәр, Чапаев урамы 2 нче йорттан 32 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Билгеләргә:
   - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты;
   - гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты – 12 ноябрь 2024 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;
   - гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты – 13 ноябрь 2024 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр
   - халык җыенының беренче һәм икенче этабын үткәрү урыны – Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 нче йорт, Кышлау авыл мәдәният йорты залы;
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
   - 2024 елның 5 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетында

гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Кышлау торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Кышлау торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне раслага:

“Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Кышлау авылы территориясен чистарту (үлән чабу), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү).”;

3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, Кышлау авылындагы урам юлларын төзекләндерү хезмәтләре өчен түләү.)

“РИЗА” “КАРШЫ”

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталыда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Кышлау авылы, Татарстан урамы 7 нче йорт адресы буенча Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты стендына урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы: А.Х.Кашшапов